**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕКАБАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2026 елның 9 апреле** **5 номер**

# КАРАР

## 16:24:160101:1070 кадастр номерлы, Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы, Советская урамы адресы буенча урнашкан җир участогыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төр буенча файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 һәм 39 статьяларына, 2023 елның 18 декабрендәге 131 ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне бүлү турында»гы Татарстан Республикасы Законына ярашлы рәвештә, территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерү, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатыннан һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең 2026 елның 10 апрелендәге «Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы, Советская урамы адресы буенча урнашкан, 16:24:160101:1070 кадастр номерлы җир участогыннан «Кибетләр» һәм «Җәмәгать туклануы» өчен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төр буенча файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында»гы 3365/исх номерлы хаты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. 1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы, Советская урамы адресы буенча урнашкан, мәйданы 936 кв. м булган, 16:24:160101:1070 кадастр номерлы җир участогыннан **«Кибетләр»** һәм **«Җәмәгать туклануы»** өчен шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төр буенча файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирлекләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә **2026 елның 5 маена сәгать 15.00-дә** ТР, Лаеш

муниципаль районы, Олы Кабан авылы, Җиңү урамы, 5 нче йорт адресы буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне язма рәвештә **2026 елның 4 маена кадәр** ТР, Лаеш районы, Кече Кабан авылы, Южная урамы, 1 нче йорт адресы буенча җибәрергә кирәклеген билгеләргә.
4. Әлеге Карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (https://laishevo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
6. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы**
**вазыйфаларын башкаручы: Э.Р. Мөхәммәткулов**